**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НОВОТРОИЦК» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«05» декабрь 2022 ел № 26/2

## 2023 елга, 2024, 2025 еллар планы чорына Новотроицк авыл җирлеге бюджеты турында

1 статья

1. 2023 елга Новотроицк авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Новотроицк авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 16 757,7 мең сум;

2) Новотроицк авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 16 757,7 мең сум.

3) Новотроицк авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0 сум.

2. 2024, 2025 елларга Новотроицк авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Новотроицк авыл җирлеге бюджет керемнәренең гомуми күләме 2024 елга 17 281,4 мең сум, 2025 елга 17 844,1 мең сум;

2) Новотроицк авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен:

- 2024 елга 17 281,4 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 424,26 мең сум;
- 2025 елга 17 844,1 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 876,33 мең сум.

3) 2024 елга Новотроицк авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 сум һәм 2025 елга 0 сум.

3. Новотроицк авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын расларга:

- 2023 елга әлеге карарга 1 кушымта нигезендә;
- 2024 һәм 2025 еллар планы чорына әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.

2 статья

1. 2024 елның 1 януарена Новотроицк авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

2. 2025 елның 1 януарена Новотроицк авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

3. 2026 елның 1 януарена Новотроицк авыл җирлеге эчке муниципаль бурычының югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә расларга.

3 статья

1. Новотроицк авыл җирлеге бюджетында 2023 елга фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 3 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

2. Новотроицк авыл җирлеге бюджетында 2024 һәм 2025 еллар планы чорына

фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 4 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясы нигезендә Новотроицк авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен расларга:

- 2023 елда 66,2 мең сум;
- 2024 елда 113,6 мең сум;
- 2025 елда 152,2 мең сум.

2. 2023 елда һәм 2024, 2025 еллар планы чорында Новотроицк авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара субсидияләрне күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

5 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 статьясы нигезендә Новотроицк авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- төзекләндерү кысаларында авыл җирлекләре автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кышкы чистарту) буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тапшыруга 2023 елга – 1 500,0 мең сум, 2024 елда – 1 500,0 мең сум, 2025 елда 1 500,0 мең сум күләмендә;
- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ялны оештыру өчен шартлар тудыру буенча чараларны тәэмин итүгә төзелгән килешүләр буенча 2023 елга – 1 933,0 мең сум, 2024 елга – 1 933,0 мең сум, 2025 елга 1 933,0 мең сум күләмендә.

2023-2025 елда бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

6 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.13 статьясы нигезендә чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен, Новотроицк авыл җирлеге бюджетыннан Тукай муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен 2023 елга – 6 001,95 мең сум, 2024 елга – 6 452,25 мең сум, 2025 елга 6 954,65 мең сум күләмендә расларга.

7 статья

1. Новотроицк авыл җирлеге чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

- 2023 елга елга әлеге карарга 5 кушымта нигезендә;
- 2024, 2025 еллар планы чорына әлеге карарга 6 кушымта нигезендә.

2. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга:

- 2023 елга елга әлеге карарга 7 кушымта нигезендә;
- 2024, 2025 еллар планы чорына әлеге карарга 8 кушымта нигезендә.

3. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнарының максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне расларга:

- 2023 елга елга әлеге карарга 9 кушымта нигезендә;
- 2024, 2025 еллар планы чорына әлеге карарга 10 кушымта нигезендә.

4. Новотроицк авыл җирлеге бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2023 елга – 0 сум, 2024 елга – 0 сум, 2025 елга 0 сум күләмендә расларга.

8 статья

Новотроицк авыл җирлеге бюджетында җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр күләмен 2023 елга – 5,0 мең сум; 2024 елга – 5,0 мең сум, 2025 елга 5,0 мең сум күләмендә расларга.

9 Статья

Новотроицк авыл җирлеге бюджетында 2023 елга җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу өчен муниципаль районнар бюджетларына 294,7 мең сум күләмендә субвенцияләр күләмен исәпкә алырга; 2024 елга 306,0 мең сум, 2025 елга 312,0 мең сум күләмендә.

10 статья

2023 елда Новотроицк авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

11 статья

Новотроицк авыл җирлеге бюджеты калдыклары Новотроицк авыл җирлеге исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә (әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2023 елда түләнергә тиеш) файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2023 елда, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

12 статья

Әлеге карарны Новотроицк авылы (Ленин урамы, 16 й.) территориясендә урнашкан махсус стендларда урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

13 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Тукай муниципаль районы буенча территориаль органнары төзелгән килешүләр нигезендә Новотроицк авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

14 статья

Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы урынбасары А. А. Зверева